# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы
Коноваловка авыл җирлеге Коноваловка торак пунктында
2024 елда гражданнардан үзара салым кертү турында

**30.11.2022ел** **№ 2**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының Коноваловка авыл җирлегенең Коноваловка торак пунктында гражданнар җыены

**КАРАР ЧЫГАРДЫ:**

1.Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Коноваловка авыл җирлегенең Коноваловка торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 2024елда 500 сум күләмендә үзара салым кертергә,1 һәм 2 төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы һәм сугыш хәрәкәтләре ветераннарыннан, Бөек Ватан сугышы һәм сугыш хәрәкәтләрендә катнашучыларның тол хатыннарыннан, күп балалы гаиләләрдән, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан, Россия Армиясе сафларына чакырылган гражданнардан, мобилизацияләнгәннәр һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш.

2.Җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча хәл итүгә юнәлтергә:

-Коноваловка торак пунктында җәйге вакытта территориядә үләнне чаптыру (килешү буенча хезмәт өчен түләү);
- Коноваловка торак пунктында татар зиратына капка сатып алу һәм урнаштыру (килешү буенча хезмәт түләү) ;
-Коноваловка торак пунктында зиратлар өчен контейнерлар сатып алу (килешү буенча хезмәт өчен түләү);
- Коноваловка торак пунктында Яңа елга урам бизәү әйберләрен сатып алу (светодиодлы фигуралар сатып алу, килешү буенча хезмәт өчен түләү).

3.Коноваловка авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән әлеге карарны игълан итәргә, Минзәлә муниципаль районының рәсми сайтында http://menzelinsk.tatarstan.ru, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми сайтында http://pravo.tatarstan.ru кабул ителгән көннән алып 10 көн эчендә бастырып чыгарырга.

Халык җыенында рәислек итүче,
Коноваловка авыл җирлеге башлыгы урынбасары_____________ И.И.Шагиев